ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында» 427-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында» 427-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 1996-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

**Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

1 статья. **Әлеге Законны җайга салу предметы**

Әлеге Закон хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне (алга таба – дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкил) билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү, билгеләүне һәм сайлау өчен тәкъдим итүне килештерү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне, шулай ук күрсәтелгән затларның хуҗалык җәмгыятьләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектлары буенча тавыш бирүдә позициясен килештерү мәсьәләләрен җайга сала.

2 статья. **Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр эшчәнлегенең хокукый нигезләре**

Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр үз эшчәнлекләрен федераль законнар, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү, билгеләү һәм сайлау өчен тәкъдим итүне килештерү һәм әлеге затлар тарафыннан хуҗалык җәмгыятьләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектлары буенча тавыш бирүдә позицияләрне килештерү тәртибен билгели торган башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыралар.

3 статья. **Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләргә карата гомуми таләпләр, аларны хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү, билгеләү һәм сайлау өчен тәкъдим итүне килештерү тәртибе**

1. Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр булып Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар, шулай ук әлеге Законның 9 статьясы нигезендә башка затлар тора ала.

2. Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү, билгеләнүне һәм сайлау өчен тәкъдим итүне килештерү түбәндәге хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына карата башкарыла:

1) аларга карата махсус хокукны (алтын акция) куллану турында карар кабул ителгән;

2) акцияләре (устав капиталындагы өлешләре) Татарстан Республикасы милкендә булган;

3) аларның акцияләре (устав капиталындагы өлешләре) аларның акцияләренең (устав капиталындагы өлешләре) 50 процентган артыгы Татарстан Республикасы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләренә караган.

3. Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләү, билгеләүне килештерү түбәндәге хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына карата башкарыла:

1) аларга карата махсус хокукны (алтын акция) куллану турында карар кабул ителгән;

2) акцияләрнең (устав капиталындагы өлешләре) 100 проценты Татарстан Республикасы милкендә булган.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелмәгән очракларда, дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне сайлау өчен тәкъдим итү, сайлау өчен тәкъдим итүне килештерү гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүне түләүсез нигездә гамәлгә ашыралар.

4 статья. **Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләүне, сайлау өчен тәкъдим итүне, билгеләүне һәм сайлау өчен тәкъдим итүне килештерүне гамәлгә ашыручы органнар**

Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләүне, сайлау өчен тәкъдим итүне, билгеләүне һәм сайлау өчен тәкъдим итү гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасы Рәисе;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан.

5 статья. **Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү, билгеләү һәм сайлау өчен тәкъдим итүне килештерү**

Татарстан Республикасы Рәисе боерыгы белән гамәлгә ашырыла:

1) акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган, Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим булган хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе җитәкчесе, башкарма хакимиятнең республика органнары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында, республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү;

2) әлеге Законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына, шулай ук әлеге Законның 3 статьясының 2 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе җитәкчесе, башкарма хакимиятнең республика органнары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында, республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү;

3) әлеге Законның 3 статьясының 2 өлешендәге 3 пунктында күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләүне һәм сайлау өчен тәкъдим итүне килештерү.

6 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү, билгеләү һәм сайлау өчен тәкъдим итүне килештерү**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын әлеге Законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләре идарәсе органнарына билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү;

2) әлеге Законның 5 статьясындагы 3 пунктында һәм 7 статьясының 1 өлешендәге 1 пунктында каралган очракларда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын килештерү.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшли башлаган көнгә кадәр хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар.

7 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү, билгеләү һәм сайлау өчен тәкъдим итүне килештерү**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән гамәлгә ашырыла:

1) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән, әлеге статьяның 2 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән исемлеккә кертелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына дәүләт мәнфәгатьләрен тәкъдим итүче вәкилләрне әлеге Законның 5 статьясының 2 пунктында һәм 6 статьясының 1 өлеше 2 пунктында каралган билгеләү һәм сайлау өчен тәкъдим итүне килештерү нигезендә билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү;

2) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән, әлеге статьяның 2 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән исемлеккә кертелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына республика башкарма хакимияте органнары җитәкчеләре вазыйфаларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында, республика башкарма хакимияте органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүчеләрне дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр итеп билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү;

3) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән, аларны идарә итү органнарына билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү Татарстан Республикасының мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү органнарына республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләүне һәм тәкъдим итүне килештерү.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана:

1) аларның идарә итү һәм тикшереп тору органнарына дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр Татарстан Республикасы Рәисе белән килештергәннән соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә, сайлау өчен тәкъдим ителә торган хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге;

2) аларның идарә итү һәм тикшереп тору органнарына дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә, сайлау өчен тәкъдим ителә торган хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге.

8 статья. **Татарстан Республикасының мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимияте органы тарафыннан дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү**

Татарстан Республикасының мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимияте органы боерыгы белән гамәлгә ашырыла:

1) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү - әлеге Законның 7 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктында каралган билгеләү һәм сайлау өчен тәкъдим итүне килештерү нигезендә;

2) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында, республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, республика башкарма хакимият органнарының язма тәкъдимнәре нигезендә;

3) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән, аларның акцияләре (устав капиталындагы өлешләре) белән идарә итү юридик яки физик затлар тарафыннан ышанычлы яки башка төрдәге идарәгә тапшыруны, хуҗалык алып баруны күздә тоткан шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла торган хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләү һәм сайлау өчен тәкъдим итүне килештерү.

9 статья. **Хуҗалык җәмгыятьләре белән идарә итү һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен тәкъдим итүгә шартнамә нигезендә дәүләт мәнфәгатьләрен тәкъдим итү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлардан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән квалификация таләпләренә җавап бирүче башка затлар да дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр итеп билгеләнергә мөмкин.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән башка затлар хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында милек мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы белән гражданлык законнары нигезендә төзелә торган Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итү шартнамәсе нигезендә дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүне гамәлгә ашыралар.

10 статья. **Хуҗалык җәмгыятенең идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектлары буенча тавыш бирүдә позицияне килештерү**

1. Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең милек мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы белән хуҗалык җәмгыятенең идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектлары буенча тавыш бирүдә түбәндәгеләр буенча позицияне язма рәвештә килештерергә тиешләр:

1) хуҗалык җәмгыятенең оештыру документларына үзгәрешләр кертү;

2) хуҗалык җәмгыятен бетерү һәм үзгәртеп кору;

3) хуҗалык җәмгыятенең устав капиталы күләмен үзгәртү;

4) хуҗалык җәмгыятенең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына конкрет затларны билгеләү, сайлау, хуҗалык җәмгыятенең бердәнбер башкарма органын булдыру, хуҗалык җәмгыятенең бердәнбер башкарма органы белән хезмәт килешүе шартларын раслау, шул исәптән хуҗалык җәмгыятенең социаль-икътисадый хәле күрсәткечләренә (индикаторларына) ирешү турында, хуҗалык җәмгыятенең бердәнбер башкарма органына бүләкләү (премияләр яки башка түләүләр) күләмен һәм тәртибен билгеләү, хуҗалык җәмгыятенең бердәнбер башкарма органы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

5) хуҗалык җәмгыяте тарафыннан аны гамәлгә ашыруда кызыксыну булган килешүләр төзү;

6) хуҗалык җәмгыяте тарафыннан хуҗалык җәмгыяте тарафыннан хуҗалык җәмгыяте активларының баланс бәясенең 25 һәм аннан да күбрәк процентын тәшкил итә торган милекне сатып алу яки читләштерү, шулай ук күрсәтелгән милекне ышанычлы идарә итүгә, арендага, залогка (ипотека) тапшыру белән бәйле зур сату-алу килешүе төзелү;

7) хуҗалык җәмгыятенең башка коммерция оешмаларын (шул исәптән бүлендек хуҗалык җәмгыятьләрен), финанс-сәнәгать төркемнәрен, ассоциацияләрне һәм берләшмәләрне булдыруда катнашуы;

8) хуҗалык җәмгыяте тарафыннан бәясе хуҗалык җәмгыяте активларының баланс бәясенең 10 һәм аннан да күбрәк процентын тәшкил иткән турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган милекне сатып алу, читләштерү яки хуҗалык җәмгыяте тарафыннан читләштерү мөмкинлеге белән бәйле килешү яки үзара бәйләнешле берничә килешү төзү;

9) хуҗалык җәмгыятенең күчемсез милек белән килешүләр төзүе.

2.Хуҗалык җәмгыятенең бер идарә органында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче берничә вәкил булганда хуҗалык җәмгыятенең идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектлары буенча тавыш бирүдә дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләренең бердәм позициясе алдан билгеләнә.

3. Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилнең хуҗалык җәмгыятенең идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектлары буенча тавыш биргәндә позицияләрен килештерү тәртибе, хуҗалык җәмгыятенең идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектлары буенча тавыш бирүдә дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрнең бердәм позициясен билгеләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4. Хуҗалык җәмгыятенең идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектлары буенча тавыш бирүдә билгеләнгән позицияне килештерү тәртибен бозган дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр, шулай ук килешү нәтиҗәләре белән туры килмәгән нигездә тавыш бирүчеләр законнар нигезендә җавап тоталар.

11 статья. **Татарстан Республикасының аерым закон актларын (закон актлары нигезләмәләрен) үз көчләрен югалткан дип тану**

Үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Хуҗалык җәмгыятьләре һәм ширкәтләренең идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында» 2000 елның 19 октябрендәге 383 номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 11 (9);

2) «Хуҗалык җәмгыятьләре һәм ширкәтләренең идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 12 декабрендәге 122-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы басмасы, 2005, № 12 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 7 октябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 10 (I өлеш);

4. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 6 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2023, № 27 (I өлеш).

12 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# **АҢЛАТМА**

Закон проекты «Хуҗалык җәмгыятьләре һәм ширкәтләре белән идарә итү һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында» 2000 елның 19 октябрендәге 383 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен актуальләштерү зарурлыгына бәйле рәвештә эшләнде.

Закон проекты белән дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр эшчәнлегенең хокукый нигезләре, дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләргә, хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итүгә, билгеләүне (сайлану өчен тәкъдим итү) килештерү тәртибенә гомуми таләпләр, дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләүне, сайлау өчен тәкъдим итүне, билгеләүне (сайлау өчен тәкъдим итүне) килештерүне гамәлгә ашыручы органнар билгеләнә.

Закон проекты хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектлары буенча тавыш биргәндә позицияләрне килештерүне таләп итүне күздә тота, шулай ук тавыш бирүдә дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрнең бердәм позициясен билгеләүне таләп итә.

Закон проектының нигезләмәләре коррупциягә каршы тору турындагы закон таләпләренә, аерым алганда, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына туры китереп эшләнгән, аның нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273 номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләр, бурычлар һәм тыюлар кагыла.

Закон проекты нигезендә, хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына дәүләт вәкилләре буларак билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз вазыйфаларын бары тик түләүсез нигездә башкаралар дип билгеләнә.

Закон проекты белән «Хуҗалык җәмгыятьләре һәм ширкәтләре белән идарә итү һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында» 2000 елның 19 октябрендәге 383 номерлы Татарстан Республикасы Законын һәм билгеләнгән законга үзгәрешләр кертү хакындагы актларны, закон актлары нигезләмәләрен үз көчләрен югалткан дип тану күздә тотыла. Алар урынына хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләү, сайлау өчен тәкъдим итү, билгеләүне (сайлау өчен тәкъдим итү) килештерү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне актуаль җайга салу билгеләнә.

**«Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы дәүләт милке турында» 2022 елның 23 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү таләп ителәчәк.

Югарыда күрсәтелгән закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларын актуальләштерү таләп ителәчәк:

«Хуҗалык җәмгыятьләре һәм ширкәтләренең идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләре белән эш буенча ведомствоара комиссия турында» 2001 елның 15 декабрендәге 895 номерлы карар;

«Акцияләре (өлешләре) Татарстан Республикасы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләренең идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру турында» 2003 елның 21 ноябрендәге 601 номерлы карар;

«Акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган һәм (яки) аларга карата махсус хокук («алтын акция») куллану турында карар кабул ителгән акционерлык җәмгыятьләре идарәсе органнарында дәүләт вәкилләренең эшчәнлеген тәртипкә китерү турында» 2007 елның 4 маендагы 172 номерлы карар;

«Хуҗалык җәмгыятьләре һәм ширкәтләренең идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында» 2000 елның 19 октябрендәге 383 номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2014 елның 16 маендагы 322 номерлы карар;

«Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм контроль органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2021 елның 2 апрелендәге 210 номерлы карар.

**«Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.